**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАР**

**утызынчы утырыш икенче чакырылыш**

**31 июль 2013 ел** **№ 76** **Олы Мәтәскә ав.**

**Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якындагы территорияләрне билгеләү турында**

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» 1995 елның 22 декабрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 декабрендәге 1425 номерлы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнар күпләп җыела торган урыннарны һәм югары куркыныч чыганаклары булган урыннарны билгеләү, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын җирләрнең чикләрен билгеләү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы «Татарстан Республикасында халык арасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке куллануны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» карары, муниципаль район Советының «Алкогольле продукция әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясенең норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру турында» 2013 елның 09 июлендәге 46 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге территориясендә түбәндәге тәртиптә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган оешмаларга һәм (яисә) объектларга якын территорияләрне билгеләргә:

| № п/п | Объектның исеме | Җәмагать туклануы хезмәтләре күрсәтә торган стационар сәүдә объекты/объект | Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган янәшәдәге территорияләрнең күләмнәре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Балалар оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 120 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы күрсәтә торган объект | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 60 метр алып тору (ул булса) |
| 2 | Мәгариф оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 120 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 60 метр алып тору (ул булса) |
| 3 | Медицина оешмалары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| 4 | Спорт объектлары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | |
| 5 | Күпләп сату һәм ваклап сату базарлары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 30 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | |
| 6 | Вокзаллар | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 30 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | |
| 7 | Хәрби билгеләнеш объектлары | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Югары куркыныч чыганакларының урнашкан урыны, массакүләм күңел ачулар, бәйрәм итүләр, массакүләм тамашалар һәм спорт чаралары уздыру өчен билгеләнгән урыннар | Стационар сәүдә объекты | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлыннан ким дигәндә 50 метр алып китү (ул булса) |
| | | Җәмәгать туклануы хезмәтен күрсәтүче объект | Зонада объектка яки аерымланган территориягә керү юлларыннан ким дигәндә 40 метр бүлеп бирелгән (ул булганда) |

2.Расларга:

2.1. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә урта гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территория схемасын, 1 номерлы кушымта нигезендә.

2.2. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Лесной поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территория схемасын, 2 номерлы кушымта нигезендә.

2.3. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Ямбулат башлангыч мәктәбе», ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Ямбулат фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасын, 3 номерлы кушымта нигезендә.

2.4. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Тәмте-Мәтәскә башлангыч мәктәбе» янындагы территория схемасын 4 номерлы кушымта нигезендә.

2.5. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Югары Мәтәскә фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасын, 5 номерлы кушымта нигезендә.

2.6. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Олы Мәтәскә фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасын, 6 номерлы кушымта нигезендә.

2.7. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Лесной поселогы фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасын,7 номерлы кушымта нигезендә.

2.8. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБММУ «Теләче муниципаль районы Лесной поселогы балалар бакчасы» янындагы территория схемасын, 8 номерлы кушымта нигезендә.

2.9. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБММУ «Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә балалар бакчасы» янындагы территория схемасын, 9 номерлы кушымта нигезендә.

3. Гамәлдәге законнар нигезендә әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә түбәндәге адреслар буенча: Олы Мәтәскә авылы, Ф.Хөсни урамы, 56А йорт;

Югары Мәтәскә авылы клубында, Центральная урамы, 15 А йорт; Ямбулат авылы клубында, М.Ногуманов урамы, 18 йорт; Тәмте-Мәтәскә авылы клубында, Подгорная урамы, 16 йорт; Лесной поселогя клубында, Татарстан ур., 8, һәм Теләче муниципаль районы рәсми сайтында Олы Мәтәскә авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.


5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге башлыгы Вәлиуллин Миннәхмәт Абдулла улына йөкләргә.

Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә
авыл җирлеге башлыгы М.А.Вәлиуллин.

1 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә урта гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территория схемасы



2 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Лесной поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе» янындагы территория схемасы



3 номерлы кушымт

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елны
31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланга


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципал
районы Ямбулат башлангыч мәктәбе», ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе»
Ямбулат фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасы



4 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБМУ «Теләче муниципаль районы Тәмте-Мәтәскә башлангыч мәктәбе» янындагы территория схемасы



5 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Югары Мәтәскә фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасы



6 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл жирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Олы Мәтәскә фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасы



7 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган


Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» Лесной поселогы фельдшерлык-акушерлык пункты янындагы территория схемасы



8 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган

Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБММУ «Теләче муниципаль районы Лесной поселогы балалар бакчасы» янындагы территория схемасы



9 номерлы кушымта

Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2013 елның 31 июлендәге 76 номерлы карары белән расланган

Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән МБММУ «Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә балалар бакчасы» янындагы территория схемасы

